Кышнын ике ае инде артта, оченче аена кердек, ə салкынын əле генə сизə башладык. Əле генə жирне кар каплада, суык борыннарны чеметергə тотынды. Сандыклардан жылы туннар, йоннан бəйлəнгəн биялəйлəр, киез итеклəр оскə чыкты. Керосин исе килеп торса да, шундый йомшак, шундый матур иде яшьлектəге киез итеклəр! Шəhəргə дə бу мода буларак янадан кереп бара. Сарык йонынннан баскан итеклəрнен жылылыгы, ə файдасы турында сойлəп тору тvгел, киеп йорисе бар. Фабриканын тvгел, кул белəн эшлəнгəннəре турында сvз.       Аларны Мордовиянен торле почмакларында басучылар əле дə бар. 28 январьдə Темниково районындагы Аксел авылында рус халкынын «За - Валенки!» дигəн милли-мəдəни бəйрəме vтте. Максаты - милли гореф-гадəтлəрне саклау. «Народ не должен забывать свои корни, - дилəр район мəдəният, туризм, спорт həм яшьлəр сəясəте Идарəсендə. - Аксел - это село с 400-летней историей. Этот населенный пункт издавна славился шерстобойкой и валенками». Киез итеклəр конендə, əзер киез итеклəр (мəсəлəн, Василий Ковалев гаилəсе торле рəсемле киез итеклəрне басалар) белəн бергə, кул эшлəрен алып кайтучылар байтак иде həм vзешчəн ансамбльлəр, шул исəптəн унышлы «Сандугачлар» ансамбле дə   концертта катнашты, тəмле ашлар чын бəйрəм хисен уятты.

Бvген бу авылда Мамлеевлар həм Шокиннар гаилəлəре итек баса. Белгəнемчə, Темник районы Тархан авылы, Ельник районы Акчеево авылы татарлары сарык йонынннан баскан валенкаларны «оек» дип йортəлəр. Татар теленен анлатмалы сvзлегенен икенче томында итеккə тvбəндəге билгелəмə бирелгəн: итек - йоннан басылган, балтырлы киез аяк киеме; киез итек. Фитр итек- катырылган ак итек, акбур яки таш белəн агартып, матурлаганнар. Элек кичлəрен яшьлəр уенга киеп чыкканнар. Ойдə кию очен чvəк яки кəвеш сыман итеп махсус басылган яисə кунычы киселгəн итек кулланыла, аны бəлvнки (валенки) дилəр. Кvгешлелəр кvрше рус Кабаново авылы həм мукшыларнын Мордовские Пошатые итекчелəренə заказ биреп оек бастырганнар. Əйтеп китəргə кирəк, тимер юлда машинист булып эшлəгəн Кадошкино районы Иса авылы егете Кəбир Абдулла улы Уторов та гаилəсенə киез итек баса иде; туганнарына да баскалады. Кvрше Ямщина авылы валенкаларын гомер-гомергə Мордовиянен торле почмагында киеп йорvчелəр бар həм бvген дə сарык йонынннан итек басучы Михаил Лобачев, Антонина Ладанова həм башка осталар анда яши. Исемдə: беренче кар тошv белəн, эти-əнилəр кvрше Ямщина авылындагы валенки валять итvчелəргə юл тота ителəр. Авылыбыз халкы бу авылга жəяvлəп тə, ат йогелгəн чанада да йорделəр; бvген асфальт юлдан машиналарда

жилдертәләр. Гадәттә, итек басучыларнын кая яшәгәннәрен белеп, һәр ел яратып киелә торган басучыларына баралар. Һәркемнен vз мастеры – знакумы бар. Тегеләре дә котеп ала әниләребезне, заказны кабул итеп, әзер валенкаларны алырга чакырып калалар. Әле генә Темник район газетасында кvпторле бvләкләр иясе булган 47 ел стажлы механизатор һәм кvнел теләге буенча 30 ел валенки валять иткән Иске Шәһәрдә яшәvче Николай Петрович Боклашов турында укып белдем. Ул:
- Яшь чагымда авылыбызда кvпләр киез итек бастылар, - дип искә ала Николай Петрович. – Кvршем Владимир Зиновьевич Козлов та шул эш белән шогыльләнде. Үземә валенки басарга соралгач, ул: «Телисен икән, ойрәтәм», - диде. Мин килештем. Башта бик авыр булды: иртәнге дvрт сәгатьтә торып, сарык йонын юар очен, мунча яга идем. Аннары йонны калодкаларга тутырып мичтә киптерәм. Әкреп генә итек басу технологиясен ойрәндем һәм гаиләм кыш коннәрен жылы валенкалардан йорделәр. Вакыт vтv белән остардым, кулым шомарды һәм атнасына 12-14 пар киез итек бастым. Хәтта базарда сатып акча да эшләдем. Эшкә алынгач, жиренә житкереп башкарырга яратам. Сатып алучы да канәгать. Шуна да башланган эшем ремесло булып китте. Кvп кеше йонны авыллардан жыялар, ә мин сарыкларнын романовский токымын vзем vстерәм, чонки чимал сыйфаты итек басканда зур роль уйный; йомшак һәм киеп йорергә жайлы, кvнелне жылыткан итекләр булып чыксыннар. Вакыт vткәч, улым Петрга һәм киявем Юрийга да һонәр осталыгымны ойрәттем. Алар да, әтиләре тосле, эшләренә йорәк жылысын һәм кул осталыгын кушып сарык йонынннан киез итек басалар.

**Наилә Насырова**